ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.10.2023 Олы Кайбыч ав. № 426

Участоктан файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2023 елның 03 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында Хуҗа Хәсән авыл җирлеге, Хуҗа Хәсән авылы, Киров ур. адресы буенча урнашкан 16:21:140401:361 кадастр номерлы, гомуми мәйданы 38 кв.м. булган җир кишәрлеген файдалануның (күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонада «Индивидуаль җиңел автомобильләр гаражлары») шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Шартлы рөхсәт бирү турында карар проектындагы материаллар белән эш көннәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетында 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 нче кат, 209 кабинетта танышырга мөмкин.

Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 нче кат, 209 кабинетны билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар һәм материаллар уздыру турында мәгълүмат урнаштырырга;

- әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән «Кайбыч

таннары» челтәре басмасында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында, «Кайбыч таннары» («Кайбицкие зори») челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Б.Р. Сәләховка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров